**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«28» ноябрь 2025 ел № 17

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 28 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Чурабатыр торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләре һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 10 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 10 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Чурабатыр торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм

электр элемтәләре һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Чурабатыр авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Ә.Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина